بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

# Төзүчедән

Намаз – Исламның биш баганасының берсе –Аллаһы Тәгаләнең кешегә биргән чиксез нигъмәтләре өчен рәхмәт әйтү, Аллаһның Бөеклеген тану һәм Аңа буйсынуны белдерә. Намаз Мөхәммәт галәйһиссәләмгә Миграҗ кичәсендә Аллаһы Тәгалә тарафыннан турыдан-туры, арадашчысыз, бирелгән бердәнбер гыйбадәт төре.

Һәр мөселманга намаз уку тиешлеге турында Коръәннең күп аятьләрендә әйтелә. Шуларның берсен, “Ән-Ниса” сүрәсенең 103 нче аятен, искә төшерик: فَأَقِيمُواْ الصَّلاَةَ إِنَّ الصَّلاَةَ كَانَتْ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ كِتَابًا مَّوْقُوتًا (Мәгънәсе:“Намазны торгызыгыз, дөреслектә, намаз мөселманнарга билгеле вакытларда үтәлергә тиешле гамәл итеп йөкләтелде”).

Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәләмнең хәдисләрендә дә намазның әһәмияте турында күп хәбәрләр бар, мәсәлән:

- “Биш вакыт намазның мисалы - кеше үзенең ишеге яныннан аккан елгада көненә биш тапкыр коенган кебек”;

- “ Кеше тәһарәт алып фарыз намазын укыса, Аллаһ аның шул көнне  аяклары белән начар җиргә баргандагы гөнаһларын, куллары белән начарлык эшләгән гөнаһларын, колаклары белән начарлык тыңлаган гөнаһларын, күзләре белән начарлыкка караган гөнаһларын һәм күңеле белән начарлык уйлаган гөнаһларын кичерә”;

- “ Аллаһ әйтте: (Әй, Мөхәммәт!), Мин сиңа иярүчеләргә биш вакыт намазны вазифа итеп йөкләдем. Һәм Үз Үзем белән килешү төзедем: кем намазларын даими рәвештә вакытында үти, ул җәннәткә кертеләчәк. Кемнәр намазларын укымый, алар бу килешүгә кертелми”.

Мөхәммәт галәйһиссәләмнән Сәубән исемле сахабә: “Аллаһ мине җәннәткә кертә торган бер гамәл өйрәт әле”, - дип сорагач, пәйгамбәребез галәйһиссәләм аңа: “Аллаһны зурлап күп сәҗдә кыл! Чөнки Аңа кылган һәр сәҗдә саен Аллаһы Тәгалә сине бер баскычка күтәрә һәм бер гөнаһыңны кичерә”, - дигән. Икенче бер сахабәсенә Мөхәммәт галәйһиссәләм әйткән: “Әгәр алдагы дөньяда минем белән бергә булырга теләсәң, сәҗдәләреңне арттыр!”

Әлеге брошюра Исламдагы иң зур гыйбадәтләрнең берсе булган намаз укырга үзлектән өйрәнгәндә ярдәмлек буларак тәкъдим ителә. Өйрәнергә уңайлы булсын өчен, ул таблица формасында төзелгән. Беренче баганада намаздагы хәрәкәтләр, гәүдәнең торышы нинди булырга тиешлеге аңлатылган һәм  рәсем белән күрсәтелгән. Икенче баганада намаз укыганда әйтелергә тиешле зикерләрнең (Коръән сүрәләре, салаватлар, догалар һ.б.) гарәпчә язылышы, ә өченче баганада аларның транскрипциясе бирелгән. Искәртеп үтәбез, зикерләрнең транскрипциядәге язылышы гарәп хәрефләренең әйтелешен тулысынча биреп бетерә алмый. Шунлыктан, намаз эчендәге зикерләрне дөрес әйтү өчен гарәп хәрефләрен өйрәнү зарур. Ә дүртенче баганада зикерләрнең тәрҗемәсе белән танышырга мөмкин. “Аңлатмалар” бүлегендә намаз эчендәге гәүдә торышы, хәрәкәтләр тулырак тасвирлана.

Таблица үзенең универсальлеге белән аерылып тора, аны файдаланып барлык фарыз, ваҗиб һәм сөннәт намазларын да укырга өйрәнергә мөмкин. “Намазларның төрләре һәм уку рәвешләре” бүлегендә конкрет намазны укыганда таблицаның кайсы пунктларын үтәргә кирәклеге күрсәтелгән.

Намаз укырга җиңеллек белән өйрәнеп, әлеге зур гыйбадәтне Аллаһы Тәгалә кабул кылырлык итеп үтәп яшәргә насыйп булсын!

Алсу Мөхәммәтшина

## Аңлатмалар

Кыям – туры басып тору. Ирләр кулларын кушып кендектән бераз түбәнрәк куя (уң кул сул кул өстендә), хатын-кызларның куллары күкрәк өстендә.  Аяк табаннары  бер-берсеннән дүрт бармак сыярлык ераклыкта, күзләр сәҗдә буласы урынга гына карый.
Рүкүгъ – билдән бөгелү. Ирләр бармакларын аерып, кулларын тез өстенә куя, җилкәләре һәм аяклары арасында 90 градуслы почмак ясап, билдән бөгелә. Хатын-кызлар  әзрәк иелә, аяклары тездән бераз бөгелгән. Куллар шулай ук тез өстенә куела, ләкин бармаклар аерылмый.
Сәҗдә – "Аллаһү Әкбәр"  дигәннән соң,  башта тезләр, аннан соң куллар, ахырдан маңгай һәм борын намазлыкка тия. Куллар баш турысына куела. Ирләрнең беләкләре, эчләре, ботлары намазлыкка һәм кабыргаларына тими, хатын-кызлар, киресенчә, кысылыбрак сәҗдә кыла. Аяк бармаклары кыйблагат каратып куела.
Кагъдә – утырып тору. Ирләр сул аяклары өстенә утырып, уң аякларын бастырып, бармакларын кыйблага каратып куя, куллар тез өстендә. Хатын-кызлар ике аякларын да уң якка чыгарып, сул якка утыра, бармакларын кыйблага каратып куя.


# Намазларның төрләре һәм уку рәвешләре


1. Иртәнге намазның ике рәкәгать сөннәте: таблицаның 1 - 32, 59 – 64 пунктларында язылганнарны үтәргә кирәк.
2. Иртәнге намазның ике рәкәгать фарызы: 1 - 32, 59 – 64.
3. Өйлә намазының дүрт рәкәгать сөннәте: 1 – 64.
4. Өйлә намазының дүрт рәкәгать фарызы: 1 – 64 (35, 47 укылмый).
5. Өйлә намазының ике рәкәгать сөннәте: 1 – 32, 59 – 64.
6. Икенде намазының дүрт рәкәгать фарызы: 1 – 64 (35, 47 укылмый).
7. Ахшам намазының өч рәкәгать фарызы: 1 – 34, 49 – 64.
8. Ахшам намазының ике рәкәгать сөннәте: 1 - 32, 59 – 64.
9. Ястү намазының дүрт рәкәгать фарызы: 1 – 64 (35, 47 укылмый).
10. Ястү намазының ике рәкәгать сөннәте: 1 - 32, 59 – 64.
11. Өч рәкәгать витр вәҗиб намазы: 1 – 35, 47, 65, 49 – 64.

# Намаз уку тәртибе


| № | Гәүдәнең торышы һәм хәрәкәтләр | Зикернең гарәпчә язылышы | Зикернең транскрипциясе | Зикернең тәрҗемәсе |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кыйблага карап, намазлык өстенә басарга. Аяк табаннары арасында дүрт бармак сыярлык ара калдырырга.  | أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ | Әгүүзү* биЛләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим | Куылган шайтаннан Аллаһка сыенам |
| 2 |  | بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ | БисмиЛләәһир-Рахмәәнир-Рахиим | Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһ исеме белән |
| 3 |  | | Ният:<br>- Иләһи, ният кылдым (иртәнге, өйлә, икенде, ахшам, ястү) намазының (ике, өч, дүрт) рәкәгать (сөннәтен, фарызын) укырга;<br>-Юнәлдем кыйбла тарафына | Ният:<br>- Иләһи, ният кылдым (иртәнге, өйлә, икенде, ахшам, ястү) намазының (ике, өч, дүрт) рәкәгать (сөннәтен, фарызын) укырга;<br>-Юнәлдем кыйбла тарафына |
| 4 |  | خَالِصًا لِلّٰهِ تَعَالَى | Хаалисан лиЛләәһи Тәгәәләә | Аллаһ Ризалыгы өчен |
| 5 | Ирләр кулларының учларын кыйблага каратып баш бармаклары колак яфракларына тяирлек итеп күтәрәләр, аннан соң кулларын эчләренә куялар. | اَللهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Хатын-кызлар куларының учларын кыйблага каратып иң өсләренә кадәр күтәрәләр, аннан соң кулларын күкрәк өстенә куялар.<br><br>“ | | | |
| 6 | Кыям<br> | سُبْحَانَكَ اللّٰهُمَّ وَ بِحَمْدِكَ وَ تَبَارَكَ اسْمُكَ وَ تَعَالَى جَدُّكَ وَ لاَ اِلَهَ غَيْرُكَ | Сүбхәәнәкә Әллааһүммә вә бихәмдикә вә тәбәәракәСмүкә вә Тәгәәләә жәддүкә вә ләә иләәһә гайрук | Әй, Аллаһ, Сиңа дан һәм мактау булсын. Синең исемең мөбарәк һәм дәрәҗәң олуг. Синнән башка бернинди Иләһи зат юк. |
| 7 | Кыям<br> | اَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ | Әгүүзү биЛләәһи миннәшәйтаанир-ражииим | Куылган шайтаннан Аллаһка сыенам |
| 8 | Кыям<br> | بِاسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَانِ الرَّحِيمِ(1) الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ(2)الرَّحْمَانِ الرَّحِيمِ(3)مَالِكِيَوْمِالدِّينِ(4)إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّا كَنَسْتَعِينُ(5)اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ(6)صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلَا الضَّالِّينَ(7) | “Әл-Фәтихә” сүрәсе:<br>1. БисмиЛләәһир-Рахмәәнир-Рахиим<br>2. Әлхәмдү лиЛләәһи Раббил гәәләмиин<br>3. Әр-Рахмәәнир Рахиим<br>4. Мәәлики йәүмиддиин<br>5. Иййәәкә нәгбүдү үә иййәәкә нәстәгыййн<br>6. Иһдинәс сыйраатал мүстәкыййм<br>7. Сыйраатал ләзиинә әнгәмтә гәләйһим гайриль мәгъдууби гәләйһим вә ләд-даааааллиииин. Әәмиин. | 1. Рәхимле шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм.<br>2. Барча мактау - галәмнәрнең Раббысы Аллаһка.<br>3. Аллаh – Рәхимле, Шәфкатьле.<br>4. Аллаh - Ахирәт көненең патшасы.<br>5. Без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз.<br>6. Безне туры юлга күндер.<br>7. Шуларның юлына – кемнәргә Син нигъмәт бирдең. Ачуың төшкән һәм юлдан язучылар юлына күндермә. |
| 9 | Кыям<br> | إِنَّا أَعْطَيْنَاكَ الْكَوْثَرَ(1)فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ(2)إِنَّ شَانِئَكَ هُوَ الْأَبْتَرُ(3) | “Әл-Кәүсәр” сүрәсе:<br>1. Иннәә әгтайнәәкәл кәүсәр<br>2. Фәсалли лиРаббикә үәнхәр<br>3. Иннә шәәниәкә һүәл әбетәр. | Дөреслектә, Бирдек сиңа Кәүсәрне. Раббың Ризалыгы өчен намаз укы һәм корбан чал! Дөреслектә, сине кимсетүче үзе нәселсез. |
| 10 | Кыямнан | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | рукүгъка күчү | | | |
| 11 | Рукүгъ  | سُبْحانَ رَبِّىَ الْعَظِيم | Сүбхәәнә Рабби-әль-Гәзыййм (3 тапкыр) | Олугъ Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 12 | Рукүгъдан кыямга күчү | سَمِعَ اللهُ لِمَنْ حَمِدَهُ | СәмигАллааһу лимән хәмидәһ | Аллаһ Үзен мактаучыны ишетә |
| 13 | Кыям  | رَبَّناَ لَكَ الْحَمْدُ | Раббәнәә ләкәл-хәмд | Раббыбыз, барча мактау - Сиңа гына. |
| 14 | Кыямнан сәждәгә күчү | اَللهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 15 | Сәждә  | سُبْحانَ رَبِّى الاعْلٰى | Сүбхәәнә Рабби-әль-Әглә (3 тапкыр) | Бөек Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 16 | Маңгайны җирдән аерып, тезләнеп утырырга, кулларны тез өстенә куярга, күзләр кулларга карый. Шул хәлдә 2-3 секунд утырып торырга.  | اَللهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 17 | Кагъдәдән сәждәгә күчү | اَللهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 18 | Сәждә  | سُبْحانَ رَبِّى الاعْلٰى | Сүбхәәнә Рабби-әль-Әглә (3 тапкыр) | Бөек Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 19 | Сәждәдән кыямга күчү | اَللهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 20 | Кыям  | بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَانِ الرَّحِيمِ(1)<br>الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ(2)الرَّحْمَانِ | Әл-Фәтихә" сүрәсе:<br>1. БисмиЛләәһир-Рахмәәнир-Рахиим<br>2. Әлхәмдү лиЛләәһи Раббил гәәләмиин<br>3. Әр-Рахмәәнир Рахиим | 1. Рәхимле шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм.<br>2. Барча мактау - галәмнәрнең Раббысы Аллаһка.<br>3. Аллаһ – Рәхимле, Шәфкатьле. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | الرَّحِيمِ(3)مَالِكِيَوْمِالدِّينِ(4)إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ(5)اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ(6)صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلَا الضَّالِّينَ(7) | 4. Мәәлики йәүмиддиин<br>5. Иййәәкә нәгбүдү үә иййәәкә нәстәгыййн<br>6. Иһдинәс сыйраатал мүстәкыййм<br>7. Сыйраатал ләзиинә әнгәмтә гәләйһим гайрил мәгъдууби гәләйһим вә ләд-даааааалииииин. Әәмиин. | 4. Аллаһ - Ахирәт көненең патшасы.<br>5. Без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз.<br>6. Безне туры юлга күндер.<br>7. Шуларның юлына – кемнәргә Син нигъмәт бирдең. Ачуың төшкән һәм юлдан язучылар юлына күндермә. |
| 21 | Кыям<br> | قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ(1)اللَّهُ الصَّمَدُ(2)لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ(3)وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ(4) | -“Әл-Ихләс” сүрәсе:<br>1. Куль ҺүәЛлааһү Әхәде<br>2. Аллааһүс Самәде<br>3. Ләм йәлиде үә ләм йүүләде<br>4. Үә ләм йәкүлләҺүү куфүүән әхәде. | 1. Әйт: Ул Аллаһ – Бер генә,<br>2. Аллаһ бер нәрсәгә дә мохтаҗ түгел.<br>3. Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады.<br>4. Һәм Аңа тиңдәш бер зат та булмады. |
| 22 | Кыямнан рукүгъка күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 23 | Рүкүгъ<br> | سُبْحانَ رَبِّىَ الْعَظِيم | Сүбхәәнә Рабби-эль-Гәзыййм (3 тапкыр) | Олугъ Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 24 | Рүкүгъдан кыямга күчү | سَمِعَ اللهُ لِمَنْ حَمِدَهُ | СәмигАллааһу лимән хәмидәһ | Аллаһ Үзен мактаучыны ишетә |
| 25 | Кыям<br> | رَبَّناَ لَكَ الْحَمْدُ | Раббәнәә ләкәл-хәмд | Раббыбыз, барча мактау - Сиңа гына. |
| 26 | Кыямнан сәҗдәгә күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 27 | Сәҗдә<br> | سُبْحانَ رَبِّى الاعْلٰى | Сүбхәәнә Рабби-эль-Әглә (3 тапкыр) | Бөек Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 28 | Маңгайны җирдән аерып, тезләнеп утырырга, кулларны тез өстенә куярга, | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күзләр кулларга карый. Шул хәлдә 2-3 секунд утырып торырга.  | | | |
| 29 | Кагъдәдән сәҗдәгә күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 30 | Сәҗдә  | سُبْحانَ رَبِّىَ الاعْلٰى | Сүбхәәнә Рабби-эль-Әглә (3 тапкыр) | Бөек Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 31 | Сәҗдәдән кагъдәгә күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 32 | Кагъдә  | اَلتَّحِيَّاتُ لِلّٰهِ و الصَّلَوَاتُ و الطَّيِّبَاتُ اَلسَّلامُ عَلَيْكَ اَيُّهَا النَّبِىُّ وَ رَحْمَةُ اللهِ وَ بَرَكَاتُهُ اَلسَّلامُ عَلَيْنَا وَ عَلَى عِبَادِ اللهِ الصَّالِحِينَ اَشْهَدُ اَنْ لا اِلَهَ اِلاَّ اللهُ وَ اَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُه وَ رَسُولُهُ | Әт-тәхиййәәтү лиЛләәһи вәссаләүәәтү вәт-таййибәәт. әссәләәмү гәләйкә әййүһән-нәбийү вә рахмәтүЛлааһи вә бәракәәтүһ. әссәләәмү гәләйнәә үә гәләә гыйбәәдиллләәһис-саалихиин. Әшһәдү әл-ләә иләһә илләЛлааһү вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһ | Сәламнәр, гыйбәдәтләр, хәерле эшләр - һәркайсы Аллаһ өчен. Әй, пәйгамбәребез, сиңа Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын. Сәлам безгә дә һәм Аллаһның һәрбер изге бәндәләренә дә булсын. Аллаһтан башка Иләһ юк дип шаһитлек бирәм, Мүхәммәд галәйһиссәләм Аллаһның колы һәм илчесе дип шаһитлек бирәм. |
| 33 | Кагъдәдән кыямга күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 34 | Кыям  | بِاِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَانِ الرَّحِيمِ(1) الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ(2)الرَّحْمَانِ الرَّحِيمِ(3)مَالِكِيَوْمِالدِّينِ(4)إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ(5)اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ(6)صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ | Әл-Фәтихә" сүрәсе:<br>1. БисмиЛләәһир-Рахмәәнир-Рахиим<br>2. Әлхәмду лиЛләәһи Раббил гәәләмиин<br>3. Әр-Рахмәәнир Рахиим<br>4. Мәәлики йәүмиддиин<br>5. Иййәәкә нәгбүдү үә иййәәкә нәстәгыййн<br>6. Иһдинәс сыйрааталь мүстәкыййм<br>7. Сыйрааталь ләзиинә әнгәмтә гәләйһим гайриль мәгъдууби гәләйһим вә ләд-дааааааллииииин. Әәмиин. | 1. Рәхимле шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм.<br>2. Барча мактау - галәмнәрнең Раббысы Аллаһка.<br>3. Аллаһ – Рәхимле, Шәфкатьле.<br>4. Аллаһ - Ахирәт көненең патшасы.<br>5. Без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз.<br>6. Безне туры юлга күндер.<br>7. Шуларның юлына – кемнәргә Син нигъмәт бирдең. Ачуың төшкән һәм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلَا الضَّالِّينَ(7) | | юлдан язучылар юлына күндермә. |
| 35 | Кыям<br> | قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ(1)مِنْ شَرِّ مَا<br>خَلَقَ(2)وَمِنْ شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا<br>وَقَبَ(3)وَمِنْ شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي<br>الْعُقَدِ(4)وَمِنْ شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ(5) | “Әл-Фәләк” сүрәсе:<br>1. Куль әгүүзү биРаббиль фәләко<br>2. Миңң шәрри мәә халәко<br>3. Үә миңң шәрри гаасикыйн изәә үәкабе<br>4. Үә миңң шәрринн нәффәәсәәти филь гүкаде<br>5. Үә миңң шәрри хәәсидин изәә хәсәде. | 1. Әйт: ”Мин таңның Раббысы булган Аллаһка сыенам:<br>2. Ул яралткан нәрсәләрнең начарлыгыннан,<br>3. караңгылык белән дөньяны каплаган төннең зарарыннан,<br>4. төеннәргә сихер укып өрүче хатын-кызларның зарарыннан,<br>5. көнләшүче кешенең, көнләшеп гамәл кылуыннан. |
| 36 | Кыямнан рукүгъка күчү | اَللهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 37 | Рукүгъ<br> | سُبْحانَ رَبِّىَ الْعَظِيم | Сүбхәәнә Рабби-эль-Гәзыййм (3 тапкыр) | Олугъ Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 38 | Рукүгъдан кыямга күчү | سَمِعَ اللهُ لِمَنْ حَمِدَهُ | СәмигАллааһу лимән хәмидәһ | Аллаһ Үзен мактаучыны ишетә |
| 39 | Кыям<br> | رَبَّناَ لَكَ الْحَمْدُ | Раббәнәә ләкәл-хәмд | Раббыбыз, барча мактау - Сиңа гына. |
| 40 | Кыямнан сәждәгә күчү | اَللهُ اَكْبَر | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 41 | Сәждә<br> | سُبْحانَ رَبِّى الاعْلى | Сүбхәәнә Рабби-эль-Әглә (3 тапкыр) | Бөек Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 42 | Маңгайны җирдән аерып, тезләнеп утырырга, кулларны тез өстенә куярга, күзләр кулларга карый. Шул хәлдә 2-3 секунд утырып торырга. | اَللهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| |  | | | |
| 43 | Кагъдәдән сәҗдәгә күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 44 | Сәҗдә<br> | سُبْحانَ رَبِّى الاعْلى | Сүбхәәнә Рабби-әль-Әглә (3 тапкыр) | Бөек Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 45 | Сәҗдәдән кыямга күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 46 | Кыям<br> | بِاسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَانِ الرَّحِيمِ(1)<br>الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ(2)الرَّحْمَانِ<br>الرَّحِيمِ(3)مَالِكِيَوْمِالدِّينِ(4)إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ<br>نَسْتَعِينُ(5)اهْدِنَا الصِّرَاطَ<br>الْمُسْتَقِيمَ(6)صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ<br>غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلَا الضَّالِّينَ(7) | “Әл-Фәтихә” сүрәсе:<br>1. БисмиЛләәһир-Рахмәәнир-Рахиим<br>2. Әлхәмдү лиЛләәһи Раббил гәәләмиин<br>3. Әр-Рахмәәнир Рахиим<br>4. Мәәлики йәүмиддиин<br>5. Иййәәкә нәгбүдү үә иййәәкә нәстәгыййн<br>6. Иһдинәс сыйрааталь мүстәкыййм<br>7. Сыйрааталь ләзиинә әнгәмтә гәләйһим гайриль мәгъдүуби гәләйһим вә ләд-дааааааллиииин. Әәмиин. | 1. Рәхимле шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм.<br>2. Барча мактау - галәмнәрнең Раббысы Аллаһка.<br>3. Аллаһ – Рәхимле, Шәфкатьле.<br>4. Аллаһ - Ахирәт көненең патшасы.<br>5. Без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз.<br>6. Безне туры юлга күндер.<br>7. Шуларның юлына – кемнәргә Син нигъмәт бирдең. Ачуың төшкән һәм юлдан язучылар юлына күндермә. |
| 47 | Кыям<br> | قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ النَّاسِ(1)مَلِكِ<br>النَّاسِ(2)إِلَهِ النَّاسِ(3)مِنْ شَرِّ<br>الْوَسْوَاسِ الْخَنَّاسِ(4)الَّذِي يُوَسْوِسُ<br>فِي صُدُورِ النَّاسِ(5)مِنَ الْجِنَّةِ<br>وَالنَّاسِ(6) | “Эн-Нәс” сүрәсе:<br>1. Куль әгүүзү биРаббин-нәәс<br>2. Мәликин-нәәс<br>3. Иләәһин-нәәс<br>4. Миңң шәрриль үәсүәәсил ханнәәс<br>5. Әлләзии йүүәсүисү фии судүүриннәәәс<br>6. Минәл-җиннәти үән-нәәс. | 1. Әйт: “Сыенам кешеләрнең Раббысына,<br>2. кешеләрнең Патшасына,<br>3. кешеләрнең Иләһәсенә,<br>4. вәсвәсә кылучы ханнәснең начарлыгыннан<br>4. кайсы кешеләрнең күңелләрендә вәсвәсә кыла<br>5. ул ханнәс җеннәрдән дә, кешеләрдән дә бар. |
| 48 | Кыямнан рүкүгъка күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 49 | Рүкүгъ<br> | سُبْحانَ رَبِّىَ الْعَظِيم | Сүбхәәнә Рабби-әль-Гәзыййм (3 тапкыр) | Олугъ Раббым кимчелекләрдән пакъ. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 50 | Рукугъдан кыямга күчү | سَمِعَ اللهُ لِمَنْ حَمِدَهُ | СәмигАллааһу лимән хәмидәһ | Аллаһ Үзен мактаучыны ишетә |
| 51 | Кыям<br> | رَبَّناَ لَكَ الْحَمْدُ | Раббәнәә ләкәл-хәмд | Раббыбыз, барча мактау - Сиңа гына. |
| 52 | Кыямнан сәждәгә күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 53 | Сәждә<br> | سُبْحانَ رَبِّى الاعْلٰى | Сүбхәәнә Рабби-эль-Әглә (3 тапкыр) | Бөек Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 54 | Маңгайны җирдән аерып, тезләнеп утырырга, кулларны тез өстенә куярга, күзләр кулларга карый. Шул хәлдә 2-3 секунд утырып торырга.<br> | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 55 | Кагъдәдән сәждәгә күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 56 | Сәждә<br> | سُبْحانَ رَبِّى الاعْلٰى | Сүбхәәнә Рабби-эль-Әглә (3 тапкыр) | Бөек Раббым кимчелекләрдән пакъ. |
| 57 | Сәждәдән кагъдәгә күчү | اَللّٰهُ اَكْبَرُ | Аллааһү Әкбәр | Аллаһ Олугъ |
| 58 | Кагъдә<br> | التَّحِيَّاتُ لِلّٰهِ و الصَّلَوَاتُ و<br>الطَّيِّبَاتُ السَّلامُ عَلَيْكَ اَيُّهَا النَّبِىُّ<br>وَ رَحْمَةُ اللهِ وَ بَرَكَاتُهُ اَلسَّلامُ عَلَيْنَا<br>وَ عَلَى عِبَادِ اللهِ<br>الصَّالِحِينَ اَشْهَدُ اَنْ لا اِلَهَ اِلاَّ اللهُ | Әт-тәхиййәәтү лиЛләәһи вәссаләүәәтү вәт-тайййибәәт. әссәләәмү гәләйкә әййүһән-нәбийү вә рахмәтүлЛааһи вә бәракәәтүһ. әссәләәмү гәләйнәә үә гәләә гыйбәәдилләәһис-саалихиин. Әшһәдү әл-ләә иләһә илләЛлааһү вә әшһәду әннә Мүхәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһ | Сәламнәр, гыйбәдәтләр, хәерле эшләр - һәркайсы Аллаһ өчен. Әй, пәйгамбәребез, сиңа Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын. Сәлам безгә дә һәм Аллаһның һәрбер изге бәндәләренә дә булсын. Аллаһтан башка Иләһ юк дип шаһитлек бирәм, Мүхәммәд галәйһиссәләм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | وَ اَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُه وَ رَسُولُهُ | | Аллаһның колы һәм илчесе дип шаһитлек бирәм. |
| 59 | Кагъдә  | اللهمَّ صَلِّ عَلَىَ مُحَمَّدٍ وَ عَلَى آلِ مُحَمَّدٍ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى اِبْرَاهِيمَ وَ عَلَى آل اِبْرَاهِيم اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ اللهمَّ بَارِكْ عَلَىَ مُحَمَّدٍ وَ عَلَى آلِ مُحَمَّدٍ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى اِبْرَاهِيمِ وَ عَلَى آل اِبْرَاهِيمِ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ | Аллааһүммә салли гәләәә Мүхәммәдин вә гәләә әәли Мүхәммәд, кәмәә салләйтә гәләә Ибраалиимә вә гәләә әәли Ибраалиимә иннәкә Хәмиидүм Мәҗид. Аллааһүммә бәәрик гәләә Мүхәммәдин вә гәләә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә гәләә Ибраалиимә вә гәлә әәли Ибраалиимә иннәкә Хәмидүм Мәҗид | Йә, Аллаһ, Ибраһим галәйһиссәләмгә һәм аның гаиләсенә рәхмәтеңне биргән кебек, Мүхәммәд галәйһиссәләмгә һәм аның гаиләсенә дә рәхмәтеңне бир. Дөреслектә, Син - Мактаулы һәм Олугъ зат. Йә, Аллаһ, Ибраһим галәйһиссәләмгә һәм аның гаиләсенә бәрәкәтеңне биргән кебек, Мүхәммәд галәйһиссәләмгә һәм аның гаиләсенә дә бәрәкәтеңне бир. дөреслектә, Син - Мактаулы һәм Олугъ зат. |
| 60 | Кагъдә  | رَبَّنَا آتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِي الْآخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ | Раббәнәә этинәә фид-дуньйәә хәсәнәтәүү үә фил-әхыйрати хәсәнәтәүү үә кыйнәә гәзәәбән-нәәр. | Йә, Раббыбыз! Безгә дөньда яхшы тормыш бир һәм ахыйрәттә дә яхшы тормыш бир һәм безне ут газабыннан сакла. |
| 61 | Кагъдә (уң як иң өстенә карарга)  | السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ وَ رَحْمَةُ اللهِ | Әс-сәләәмү гәләйкүм вә рахмәтүЛлааһ | Сезгә Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын |
| 62 | Кагъдә (сул як иң өстенә карарга)  | السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ وَ رَحْمَةُ اللهِ | Әс-сәләәмү гәләйкүм вә рахмәтүЛлааһ | Сезгә Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын |
| 63 | Кагъдә (куллар дога кылырга күтәрелгән) | اَسْتَغْفِرُ اللهَ | ӘстәгъфируЛлаһ (3 тапкыр) | Йә, Аллаһ, мине кичер (гафу ит). |
| 64 | Кагъдә (куллар дога кылырга | | Аллаһүммә Әнтәс-сәләәмү үә минкәс-сәләәмү тәбәәрактә йәә Зәл-Җәләли үәл-Икраам. | Йә, Аллаһ! Син тынычлык бирүче, иминлек Синнән генә. Син – |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күтәрелгән) | | Әәмиин. | мөбарәк зат, әй, Олуглык һәм Хөрмәт иясе! |
| 65 | “Кунут” догасы<br>Доганы укый башлаганчы, 33 нче пункттан соң, кыямда торганда, кулларны түбән төшерергә, аннан соң “Аллаһү Әкбәр” дип намазны башлагандагы кебек яңадан колак турысына (хатын-кызлар – иң өстенә) күтәреп, эчкә (хатын-кызлар күкрәк өстенә) куярга<br> | اللَّهُمَّ إِنَّا نَسْتَعِينُكَ وَنَسْتَغْفِرُكَ وَ نُؤْمِنُ بِكَ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْكَ وَنُثْنِي عَلَيْكَ الخَيْرَ نَشْكُرُكَ وَلانَكْفُرُكَ<br>وَنَخْلَعُ وَنَتْرُكُ مَنْ يَفْجُرُكَ<br>اللَّهُمَّ إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَلَكَ نُصَلِّى<br>وَنَسْجُدُ وَإِلَيْكَ نَسْعَى وَنَحْفِدُ نَرْجُو<br>رَحْمَتَكَ وَنَخْشَى عَذَابَكَ إِنَّ عَذَابَكَ بِالْكُفَّارِ مُلْحِقٌ | Аллааһүммә иннәә нәстәгыйнүкә үә нәстәгъфирукә үә нүъминү бикә үә нәтәүәккәлү галәйкә үә нүснии галәйкәл-хайра нәшкүрукә үә ләә нәкфүрукә үә нәхләгу үә нәтрукү мәй-йәфҗүрук. Аллааһүммә иййәәкә нәгъбүдү үә ләкә нүсаллии үә нәсҗүдү үә иләйкә нәсгә үә нәхфиду нәрҗү рахмәтәкә үә нәхшәә гәзәәбәкә иннә гәзәәбәкә бил-күффәәри мулхикъ". | "Эй, Бөек Аллам! Без Сиңа ышынабыз, Синнән ярдәм һәм ярлыкау сорыйбыз. Безне хак юлга юнәлтүеңне телибез. Без Сиңа ышанабыз һәм кабул итәбез. Без Синең алда тәүбә итәбез. Без язмышыбызга шөкерана кылабыз. без Синең изгелегеңне мактыйбыз. Без Сиңа рәхмәтебезне белдерәбез һәм шәфкатеңне бер вакытта да онытмыйбыз. Без Сиңа хыянәттән баш тартабыз. Эй, Аллаһ, без Сиңа гыйбадәт кылабыз, Сиңа гына намаз укыйбыз. Сиңа баш иябез, Сиңа ышанабыз, Сине тыңлыйбыз. Синең миһербанлыгыңа өмет итәбез, хөкем көненнән куркабыз. Шик юк, Синең газапларың хакыйкать ишеген япкан кешеләргә барып җитәр. Сакла безне, Раббым!". |

*** -** Текстта асларына сызылган “с” һәм “з” хәрефләре сакау укыла.